Туган телем - иркә гөлем
Киндер сиңа күңел түрем!

АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ 7 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ

школа №7
г. Азнакаево

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В ТАТАРСТАНЕ
2021
ТАТАРСТАНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Азнакай районына - 90 ел
1931-2021
Азнакаевскому району- 90 лет

БУ САНДА:


Баш мөхәррир сүзе 1
Мәктәп сулышы 2
Туган телебезнең матурлыгы һәм кыйммәте 3
Төбәгебезнең юбиляр шәхесләре 4-5
“Бәхетле мин хәтта Җиргә Татар булып туган өчен...” 6
Укучыларыбыз иҗаты 7
Инстаграмм буйлап... 8


# Тел – халыкның күңел кыңгыравы


ФЕВРАЛЬ– МАРТ, 2021 НЧЕ ЕЛ




## Баш мөхәррир сүзе

Тел-кешеләр арасындагы үзара хезмәттәшлекнең һәм аралашуның мөһим коралы ул. Тел ярдәмендә без үз фикерләребезне сөйләм формасында белдерә алабыз.

Тел - аралашу чарасы гына түгел, ул һәр халыкның тарихи хәтере дә. Һәр телдә рухи мәдәният, һәр милләтнең күпгасырлык тарихы чагылыш таба. Тел - ул, һичшиксез, кешелек өчен зур бүләк!

Без бүген татар телебезнең дөньядагы иң кулай 14 тел арасында иконлеген яхшы беләбез. Татар телендә дөньяда 7 миллионлап кеше сөйләшә. Безнең Татарстанда татар теленең рәсми статусы бар һәм без моның белән чиксез горурланабыз.

Безнең мәктәптә дә 616 татар баласы белем ала. Барлыгы 671 укучының 47се – рус, 2се – чуваш һәм 1ешәр мордва, азәрбайҗан, үзбәк, таҗик, вьетнам, казах милләте вәкилләре.

“Тел-халыкның күңел кыңгыравы. Ә кыңгырау – кагылмасаң, чыңламый. Әйдәгез, шушы кыңгырауга ешрак кагыйк. Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын,” – дип бик тә дөрес һәм үтемле итеп әйткән бит яраткан язучыбыз Фәнис Яруллин.

Бу яклап мәктәбебез күңел кыңгыравын көн саен чыңлату үзәге булып тора, чөнки туган телебездә төрле әдәби чаралар, бихисап бәйгеләр, китапханә, музей сәгатьләре, күренекле якташларыбыз, төбәгебез язучылары һәм шагыйрьләре белән күнелле очрашулар һ.б.еш булып тора.

2021 нче ел - “Туган телләрне саклау, үстерү һәм халыклар бердәмлеге елы” уңаеннан чыгучы газетабыз һәр татар баласының күңеленә үтеп керә алса, җанга көч-рух өстәсә, туган телебез - татар теленә кызыксыну һәм аны яхшырак белүгә теләк уятса, без бик шат булыр идек.

<u>Фирүзә Фәнилевна Кашапова, татар теле укытучысы</u>




Кайда йөрсәм, ни кылсам да,
Горурланам халкым белән!
Яхшы беләм, яхшы беләм:
Үз телем бар татар дигән.

Кадерләрмен туган телне
Бу дөньяга килгән көннән.
Милләтемнән, татарымнан
Беркайчан да йөз чөермәм!

Кайда йөрсәм, ни кылсам да,
Горурланам халкым белән!
Яхшы беләм, яхшы беләм:
Үз телем бар татар дигән.

Шәмсия Җиһангирова

### Татар дигән

Ата-бабам рухы белән
Күңелемә иман иңгән,
Илсез, денсез маңкорт түгелмен;
Әткәм-әнкәм гомер биргән,
Күңелемә иман иңгән,-
Исемем бар татар дигән!

Бу дөньяга килгән көннән
Горурланам халкым белән:
Әткәм-әнкәм гомер биргән
Үз телем бар татар дигән.

Телем, халкым, Ватанымнан
Беркайчан да йөз чөермәм!

Бу дөньяга килгән көннән
Горурланам халкым белән:
Әткәм-әнкәм гомер биргән
Нәселем бар татар дигән.
Кайда йөрсәм, ни кылсам да,
Горурланам халкым белән!

# *Мәктәп сулышы*

18 нче февраль көнне мәктәбебездә **“Туган тел-милләт көзгесе!”** районкүләм фәнни-гамәли конференциясе буен-




ча жюри утырышы үтте. Анда 5 мәктәп укучыларының эшләре тикшерелде.

Безнең мәктәп җиңүчеләре:

1. **Яруллин Б.Р.** (6 нчы сыйныф) - **җиңүче** (җитәкчесе: Шакирова Г.М.)
2. **Илһамова Э.Н.** (9 нчы сыйныф) - **җиңүче** (җитәкчесе: Фазлыева Г.Н.)
3. **Гарипова С.Э., Закирова Р.И.** (10 нчы сыйныф) - **призёр** (җитәкчесе: Кашапова Ф.Ф.)
4. **Галләмова М.М.** (5нче сыйныф)- **җиңүче** (җитәкчесе: Ваһапова Ф.Ф)






Күренекле шагыйрь, "язмышларга буйсынмас җан" **Фәнис Яруллин музее** (Баулы шәһәре) хезмәткәре Газизуллина Гүзәл Миргазиян кызы укучыларыбыз өчен мавыктыргыч **виртуаль экскурсия** үткәрде. Шагыйрьнең гыйбрәтле язмышы, киң кырлы иҗаты турында шактый мәгълүмат алдык.





Быел **"Хәтер-2021" бәйгесе** "Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы"на һәм Азнакай районының 90 еллыгына багышланды. Финалда - 6 нчы Б сыйныфы укучысы **Сафуанова Альбина** үзе язган шигыре белән **2 нче урын** алды. Җитәкчесе: туган тел, әдәбият укытучысы **Ф.Ф.Кашапова.** Регионара бәйгедә аңа да Рәхмәт хаты тапшырылды.

Герой- шагыйрь **Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулу** уңаеннан **"Батырларның батыры син, Җәлил, Исемеңне данлый Туган ил"** темасына музейда экскурсияләр циклы үткәрелде.



Татар теленнән 1-6 нчы сыйныф укучылары өчен **«Эрудит» республика олимпиадасында** 8 укучы катнашты.



**“21 нче февраль -Туган тел көне”** уңаенннан шәһәребезнең “Туган төбәк музее” хезмәткәре Мостафина Гөлфия Данил кызы катнашында **“Иң татлы тел-туган тел”** темасына **ачык сыйныф сәгате** үткәрелде (сыйныф җитәкчесе Миршатова А.Р.)



Үзәк китапханәдә безнең мәктәп укучылары Азнакай төбәге язучы-шагыйрьләре Халидә Галимова, Марсель Гарипов, Александр Лебедев, Гөлчәчәк Садретдинова белән **“Бер очрашу-бер гомер”** исемле **әдәби кунакханәдә** булдылар.







Туган тел һәм әдәбият укытучыларының **«Туган тел» Бөтенроссия конкурсында** безнең мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Гөлназ Шакирова Гран-прига** лаек булды. Мастер-классының темасы: «Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда «Padlet» виртуаль онлайн-тактасын куллану мөмкинлекләре» Ихластан котлыйбыз!



Мәдәният үзәге хезмәткәрләре 4 нче Б сыйныфы укучылары белән **"Халкымның теле - аның күңел көзгесе"** дип аталган мавыктыргыч **әдәби иртә** үткәрделәр. Укучылар бик кызыксынып карадылар, үзләре дә теләп катнаштылар.

# Туган телебезнең матурлыгы һәм кыйммәте

## *Туган тел!*

*Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Чөнки тел-тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Аңардан да көчле, татлы, назлы, ләззәтле тел бармы икән?*

*Тел-ананың балага зур бүләге. Кешегә нәселнең, халыкның асыл сыйфатларын иң әүвәл тел тәме, тел кодрәте ярдәмендә ана бирә. Туган телне белү кирәк. Чөнки туган телдә синең әби-бабаларың, әти-әниләрең, халкың сөйләшкән һәм сөйләшә. Туган телгә хөрмәтле булганда гына кеше үз иленең, төбәгенең, гаиләсенең шәҗәрәсен тарихын аңлый ала. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү-һәр кешенең изге бурычы.*

## *Татар теле…*

*Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган – сыгылмаган, баш имәгән горур ТАТАР ТЕЛЕ!*

**Илдус Гыйләҗев**

## Туган тел

*Гомеремдә бик күп гыйлем*
*Мөгаллимнәр бирде белем,*
*Күңелемә иң якыны,*
*Укытканы - туган теле.*
*Анам сөте белән сеңгән*
*Һәрбер сузык, ымлык, сүзне,*
*Җөмләләргә оештырам,*
*Акыл тажы - мәгънә тезде.*
*Башкалар һич үпкәләмәс,*
*Телне алга куйган өчен,*
*Тәрҗемәсез кабул итәм…*
*Шуңа тәмле, күркәм, өстен!*
*Ул булганда адашмабыз,*
*Юлым туры, нурлы көнем.*
*Күз карасы кебек саклыйм*
*Анам телен, татар телен!*

# *Татар халык мәкальләре*

- *Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.*
- *Ана баланы ике кат тудыра:*
  *Бер кат - тән биреп,*
  *Икенче тапкыр-тел биреп!*
- *Иле барның теле бар*
- *Иң татлы тел- туган тел,*
  *Анаң сөйләп торган тел.*
- *Акыллының теле күңелендә,*
  *Тиленең акылы телендә.*
- *Тел-кылыч: тиешсез җирдә тый, тиешле җирдә кый.*
- *Туган телем- үзем өчен,*
  *Башка тел - көнем өчен.*
- *Телне тешләп өзеп булмый,*
  *Сөйләми дә түзеп булмый.*
- *Тел ташны эретә.*
- *Ул да яхшы, бу да яхшы,*
  *Ашаган чакта бар да яхшы,*
  *Баш коткарган тел дә яхшы.*
- *Үткен тел - бәхет,*
  *Озын тел - бәла!*

# Төбәгебезнең юбиляр шәхесләре



## Марсель Галиев

**(1946)**

**75 яшь**

Татарстанның халык язучысы, бик күп төрле хөкүмәт бүләкләре иясе, якташыбыз **Марсель Галиев** 1946 нчы елның 8 нче октябрендә Азнакай районы Балтач авылында туа. 8 нче сыйныфка кадәр ул Туйкә мәктәбендә укый. Азнакайның 1нче урта мәктәбен тәмамлагач, төзелештә рәссам - бизәүче булып эшли. Армия хезмәтеннән соң, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1974 нче елдан Татарстан Язучылар союзының пропаганда бюросында, аннан "Казан утлары" журналы редакциясенең проза бүлеге редакторы булып эшли.

Күп кенә шигырьләренә композиторлар көй яза, драмала-ры сәхнәгә куела. Аның аерым әсәрләре төрек, украин, осе-тин, үзбәк, казакъ, каракалпак, чуаш телләренә тәрҗемә ителә.

1998 нче елда "Рухият" фонды үткәргән ярышта "Догалы еллар" әсәре өчен I дәрәҗә лауреат Дипломы белән бүләкләнә.

1995 нче елда аңа "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелә. 1996 нчы елда татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен Президент Указы белән Татарстан Республикасының Мактау грамотасы тапшырыла.

**Марсель Галиев** - Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты.


### *Туган тел*

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
Былбыл сайрап кунган тел.

Елатасың, юатасың,
И туган тел, туган тел,
Кәүсәр сулар юган тел!
Әткәм нигез ташы куйган,
Әнкәм бишек корган тел.

Уйлатасың, уятасың,
И туган тел, туган тел,
Халкым кебек уңган тел!
Күктән туган иман нурын
Мәңге саклый торган тел!

Талымлы син, ягымлы син,
И туган тел, туган тел,
Халкым кебек уңган тел!
Күктән иңгән иман нурын
Мәңге саклый торган тел!



## НУР ӘХМӘДИЕВ

**(1946)**

**75 яшь**

Нур Гариф улы Әхмәдиев 1946 нчы елның 14 нче декабрендә Азнакай районының Әсәй авылында туган. Урта белемне Азнакайның 1нче урта мәктәбендә ала. 1965-70 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Университетны тәмамлаганнан соң, Азнакай районына эшкә кайта.

Сарлы сигезьеллык мәктәбендә укыта, ВЛКСМның Азнакай район комитетында, аннан район радио тапшыруларын оештыручы булып эшли.

Әдәби иҗат белән мәктәптә укыган еллардан ук шөгыльләнә. Республика матбугатында студент елларында басыла башлый.

**Нур Әхмәдиев** - Р.Төхвәтуллин исемендәге һәм “Татнефть”нең “Рухият” фонды премияләре лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

1984 нче елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

### Азнакаем - ак бишегем

Чатыр тауга менсәм, серләремне
Сөйләр идем ялгыз каенга.
Сөйгәнемнең туй күлмәге төсле
Ап-ак минем Азнакаем да.

Азнакаем – ак калам,
Җиреңнән җылы алам.
Мин бит синең кырларыңнан
Нефть чыгарган балаң.
Мин бит синең гашыйк балаң,
Бәхетемне синдә табам.

Чагыла да утлар күзләреңдә
Нуры арта тулган айның да.
Яшьлегебез, якты һәйкәл булып,
Җырга күчте Азнакаемда.

Ятимләнеп калам, Азнакайдан
Азга гына киткән саен да.
Җаннарымның әллә бер яртысы
Кала микән Азнакаемда?

# Төбәгебезнең юбиляр шәхесләре



## ИЛДУС ГЫЙЛӘҖЕВ (1946—2018)

***Тууына 75 ел***

Азнакай районының мактаулы гражданины Илдус Сабир улы Гыйләҗев1946 нчы елның 15 нче гыйнварында Азнакай районы Урсай авылында туа. 1965 нче елда Чалпы урта мәктәбен, 1970 нче елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый һәм татар теле, әдәбияты укытучысы белгечлеге алып чыга .1970 -72 нче елларда Совет Армиясе сафларында взвод командиры була.

Беренче шигырьләрен 1962 нче елда яза башлый һәм район, республика матбугатында бастырып чыгара.1987 нче елдан иҗат эше белән җитди шөгыльләнә.

**Илдус Гыйләҗев -** Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Һади Такташ, Мәхмүт Хәсәнов, Рафаил Төхвәтуллин исемендәге әдәби премияләр лауреаты.

### Горурлыгым

- Борынгылар дөрес әйткән:
Телен саткан – илен сатар.
Горурланып яшим җирдә.
Анам татар, атам татар!
Ошамавы бик тә мөмкин.
Тик горурлар саклый ала
Туган җирен, рухи милкен.
Кем соң анда, куштанланып,
Үткәннәргә яла яга?
Хурланмасаң – ихтыярың,
Табынып үп, кулын яла.
Тик кагылма, пөхтә торсын
Халкым узган юллар даны.
Болганмаган, чиста әле,
Дәвамымда – татар каны!

### Мин бәхетле

Бәхетлеме кеше дөньяда?
Нәби Дәүли

Бәхетле мин: сау - сәламәт
Гомеремне очлап киләм.
Иртәгәмә бабаларым салган
Сукмагымнан атлап керәм.
Бәхетле мин: әбелхәят,
Иман белән дөнья көтәм.
Балаларга тутык кунмас
Туган телне биреп китәм.
Бәхетле мин, хәтта җиргә
Татар булып килгән өчен;
Кеше икәнемне исбат итеп,
Көрәшергә насыйп булган
өчен...

Илдус Гыйләҗевның кызы - **Гыйләҗева Резедә Илдус кызы - үзешчән композитор, Мәхмүт Хәсәнов премиясе лауреаты.** Ул – безнең мәктәпнең алыштыргысыз музыка укытучысы да. Әтисе белән берлектә иҗат иткән “Азнакаем, Азнакай” җыентыгында төбәгебездәге авылларга багышланган җырлар туплап бирелгән.

***Илдус Гыйләҗев***

### ӨЧ ТЕРӘҮ

*Марсель Галиев һәм*
*Нур Әхмәдиевкә*

Бер үк елда туган малайлар без,
Бер үк яктан, бер үк төбәктән.
Гамәлләребез дә шундый охшаш-
Хис дулкыны кайный йөрәктә.

Чатыртауга карап өч ягыннан,
Өч хыялый өскә үрләдек;
Шуңа микән, җиңел яуландылар
Яшәешнең башка үрләре.

Хис кимесә, имеш, куәт кайта,
Өч каләмне тауга сөядек.
Туган якны Чатыр тавы белән
Горурланып һәрчак сөйләдек.

Өч терәүле җисем аумый, диләр.
Ул каләмнәр әле торамы?
Тау ишелер аның берсенә дә
Кагылмагыз... миннән сорамый...

Азнакай районына - 90 ел
1931-2021
Азнакаевскому району- 90 лет

### АЗНАКАЙ ГИМНЫ

***Илдус Гыйләҗев сүзләре***
***Резедә Гыйләҗева көе***

Басуларың уңдырышлы,
Байлыгың—кара алтын.
Эшләп яши белгән кеше
Бәхетен синдә тапты.

Чатыр тавың, елгаларың
Бизәге туган якның.
Дустанә һәм тату яши,
Азнакай, горур халкың!

Краса лугов и ширь полей -
Отрада для души моей.
Ты нефти край,щедра земля,
Азнакай - судьба моя!

**“Бәхетле мин хәтта Җиргә татар булып туган өчен...” И. Гыйләҗев**

## *Анкета*
## *“Туган телем – әткәм – әнкәмнең теле... ”*

1. Гаиләдә нинди телдә сөйләшәсез?
2. Татар телендә чыгучы нинди газета – журналлар беләсең?
3. Телевидениедән татарча нинди каналлар карыйсың?
4. Татарча бәйгеләрдә катнашканың бармы? Булса, исемнәрен яз.
5. Гаиләдә татарча газета – журналлар алдырасызмы? Нindиләр?
6. Китапханәдән күбрәк нинди телдә язылган китаплар аласың? Татарча китаплар алганың бармы? Соңгы тапкыр укыган татарча китабыңның исемен яз.
7. Мәдәният йортларына татарча концертлар карарга барганың бармы? Кемнәр җырлаган концертта булдың һәм кайчан?
8. Балалар өчен Татарстан телевидениесендә эшләп килүче “Шаян - ТВ” каналын карыйсыңмы? Аеруча кайсы тапшыру ошый һәм ни өчен?
9. Дусларың, иптәшләрең, сыйныфташларың белән нинди телдә сөйләшәсең?
10. Нинди татар халык бәйрәмнәрен беләсең, кайсыларында булганың бар?
11. Татар театрлары, спектакльләре караганың бармы? 1-2сенең исемен яз.

**Мәктәбебездә шушы анкета сораулары буенча 238 укучыдан җаваплар алынды.**

### *Нәтиҗәләр:*

1. 158 укучы гаиләдә рус һәм татар телендә, калган укучылар татар телендә генә сөйләшә икәнлеге ачыкланды.
2. “Сабантуй”, “Салават күпере”, “Маяк” (респондентларның 67%ы )
3. ТНВ, “Шаян -ТВ”, “Мәйдан”, “”Азнакай –ТВ”
4. Татарча бәйгеләрдә респондентларның нибары 35% ы катнаша (олимпиадалар, “Татарча диктант ЯЗ”, “Тукай иҗаты –рәсемнәрдә”)
5. Гаиләдә район газетасы “Маяк (50%),“Салават күпере”(10 %) алдыралар.
6.Китапханәдән русча китаплар алалар (80% респондент) Соңгы тапкыр укыган татарча китаплары—Г.Тукай шигырьләре (38%), Г. Әпсәләмов “Ак чәчәкләр” (13%).
7.Мәдәният йортларына татарча концертлар карарга барганы юк –60% укучы (кызганыч!!!). Фирдүс Тямаев, Элвин Грей, Гүзәл Уразова, Данир Сабиров, Илсия Бәдретдинова, Алсу –Азат Фазлыевлар (30%).
8.“Шаян - ТВ” каналын карамыйм -73%, сирәк –15%. “Тамчы—шоу” тапшыруы ошый – 10% .
9. Дуслары, иптәшләре, сыйныфташлары белән русча сөйләшә -80% укучы(кызганыч!)
10. Татар халык бәйрәме–Сабантуйны 90% респондент белә, һәр елны булалар, уеннарда катнашалар. “Карга боткасы”, “Нәүрүз”бәйрәмен 15 % укучы белә.
11. Татар театрлары, спектакльләре караганы бар –25 % укучы (“Зәңгәр шәл”, “Мунча ташы”)

### Шәмсия Җиһангирова
### Сиңа дәшәм, татар баласы

Сиңа дәшәм, татар баласы!
Хәтереңне, әйдә, син яңарт!
Ата-баба рухын уятып,
Тарихыңа күз сал син кабат.

Синең халкың затлы нәселдән,
Катнаштырма каның ят белән!
Анаң телен берүк онытма,
Намусыңны бәйлә хак белән.

Кирәк булса, мен син ияргә,
Тик халкыңа кара яктырма!
Нәсел каның тамган туфракка
Чит-ятлардан аяк бастырма!
Тарих исем биргән нәселеңә
Чит-ят исемнәрне тактырма!

Шунда гына якты киләчәк
Ачар сиңа сихри ал таңын.
Атың калыр килер буынга
Дәвамчысы булып татарның!

## Укучыларыбыз иҗаты



**Фәрукшина Илзирә**

### Туган телемнең тәме

Үз телемдә сөйләшүнең
Беләм ич мин тәмнәрен.
Туган телем аша тоям
Бу дөньяның ямьнәрен.
  Туган телдә аралашам
  Әти-әнием белән.
  Гаиләбездә туган телнең
  Урыны һәрчак түрдән.
"Туган телеңне онытма!"-
ди миңа әби һаман.
Зур үскәч тә, картайгач та
Онытмам, һич онытмам!
  Тел яшәсә, халкым яшәр,
  Милләт тә яшәр әле!
  Үземнең балаларым да
  "Әни!" дип дәшәр әле!

### Бабам хәтирәләре

Сугыш беткәнгә дә быел
Җитмеш биш ел тула.
Бабам еш сөйли миңа
Үз әтисе турында.
  "Кызым, синең карт бабаң
  Батыр сугышчы булган.
  Беркайчан да курыкмаган
  Дошманнарны күп кырган.
Әти сугышка киткәндә,
Миңа 10 иде бары.
Әтиләрен хәтерләми
Ул чорның балалары."
  Бабакаем сөйләгәндә,
  Минем күзләр яшьләнә.
  Аның да күңеле тула,
  Хәтирәләр яңара.
Юк, кирәкми бүтән сугыш,
Без тынычлык телибез.
Иртән гел кояш чыксын,
Кешеләр исән булсын!
  Балаларның, аналарның
  Күзләре яшьләнмәсен.
  Тыныч, имин булсын дөнья,
  Сугыш кабатланмасын!

**Хәйруллина Эльвина**

### Минем кадерле телем

И кадерле туган телем,
Сөйләшергә өйрәттең!
Үсә төшкәч, белем бирдең,
Күңелгә иман индердең.
  Бала чактан тел ачылгач,
Әкиятләр өйрәттең.
Бишек җырларын көйләп,
Шигырьләр дә сөйләттең.
  Әткәм - әнкәм өйрәткән бит
  Шуңа яратам инде.
  Горурланам телем белән
  Мәңге онытмам сине!

### Хәтер сагында

45нең мае. Илгә Җиңү килде,
Атышлар да инде тынды.
Совет солдатының батыр каны
Туган җирен саклап тамды.
  Күпме гомерләр өзелде,
  Күпме кан – яшь түгелде.
  Бу аяусыз көрәштә
  Миллионнар һәлак булды.
Фашист тоткынлыгында
Күпме әсир интекте.
Җәзалау – җәфалануны
Безнең халык күп күрде.
  76 ел үтсә дә,
  Ул еллар күңелләрдә.
  Солдатларның исеме
  Мәрмәр һәйкәлгә язылган
  һәм төренгән гөлләргә.
Мәңгелек ут янында
Сезне искә алабыз.
Һәр яз саен – бәйрәмдә
Һәйкәлгә җыелабыз.

**Сафуанова Альбина**

### Туган телем-татар теле

Туган телем-татар теле
Бала чактан җанга иңгән.
Газиз телем-татар телен
Әнкәм мирас итеп биргән.
  Моңлы бишек җырлары да
  Туган телем аша кергән.
  Тылсымлы әкиятләр дә
  Татар телем аша сеңгән.
Әткәй-әнкәй өйрәткән бит
Яратыйк без туган телне!
Ансыз безнең киләчәк юк,
Саклыйк татар телебезне!

### Салават күперенә тиң

Халкыбызның күңеле тиң
Салават күперенә.
Сокланам бай төсләренә,
Сихри бизәкләренә.
  Милли гореф-гадәтләре
  Үзләре соң ни тора!
  Туган телем - серле телем
  Һәркемне кызыктыра!

### Җиңү көне

Җитмеш алты ел сугыш
беткәнгә,
Артта калган дәһшәтле
көннәр.
Күз яшьләре белән искә ала
Ул еллар кайгысын өлкәннәр.
  Җиңү көне!
  Син – күз яшьле бәйрәм
  Шуңа күрәдер дә сагышлы.
  Күпме солдат башын салган
  яуда
  Без күрсен, дип, тыныч
  тормышны.
Бу сугышлар кабат булмасын,
Тыныч булсын туган илебез.
Аяз күкне сөрем капламасын,
Без бары тынычлык телибез!

# *ЕЛМАЙ!!! Инстаграмм буйлап…*

**“Әдәби туган як” түгәрәгенә йөрүче укучыларның кызыклы табышлары...**
























Баш мөхәррир - Кашапова Фирүзә Фәнил кызы
Гамәлгә куючы - Кашапова Фирүзә Фәнил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Адрес: 423331, ТР, Азнакай шәһәре, Мәхмүт Хәсәнов урамы, 24 нче йорт
Email: S7.Azn@edu.tatar.ru
0207000484@edu.tatar.ru